# КАРАР

23 ноябрь, 2023 ел №1

Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Бөяр поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 23 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Бөяр поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Бөяр поселогында урам юл челтәрен карап тоту, килешү буенча түләү;
2) Бөяр поселогында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм килешү буенча түләү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 7 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 5 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 5 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Бөяр поселогындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: « Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Бөяр поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Бөяр поселогында урам юл челтәрен карап тоту, килешү буенча түләү;
2) Бөяр поселогында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм килешү буенча түләү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Корбанов